# Сыйфат турында төшенчә.
# Сыйфат дәрәҗәләре.

Предметның билгесен белдереп, *нинди? кайсы? кайдагы?* кебек сорауларга җавап булган сүз төркеме **сыйфат** дип атала.

Сыйфат исемне ачыклап килә. Сыйфат ачыклап килгән исем **сыйфатланмыш** була.

Сыйфатлар җөмләдә күбрәк **аергыч** һәм **хәбәр** булып килә.

**Асыл сыйфатлар,** предметның төп билгесен белдереп,аны төсе, күләме, зурлыгы ягыннан ачыклыйлар:кызыл алма,яшел кыяр,зәңгәр күк,биек агач, озын юл.

**Нисби сыйфатлар** бер предметның икенче предметка булган мөнәсәбәтен билге итеп күрсәтәләр:кышкы урман, җәйге һава,әдәби әсәр,сәяси мәсьәлә.



# Сыйфат дәрәҗәләре.



Сыйфатлар предмет билгесенең төрле күләмдә артуын, кимүен яки уртача **дәрәҗәдә** булуын да белдереп киләләр. Бу күренеш сыйфат дәрәҗәләре дип атала. **Татар телендә** дүрт дәрәҗә бар.

**ыштыру дәрәҗәсе**. Бер предметтагы билгенең
ка предметтагы билге күләме белән
штырганда, я бераз артыграк, я азрак булуын
әтә. Чагыштыру дәрәҗәсе гади дәрәҗәдәге
фатларга -рак, -рәк кушымчалары ялгап ясала:
ил+рак — кызылрак, көчле+рәк — көчлерәк.

123RF

**Артыклык дәрәҗәсе**. Сыйфатларның бу дәрәҗәсе бер предметтагы билге күләменең башка барлык предметларга караганда күбрәк булуын белдерә. Сыйфатның **кимлек дәрәҗәсе** предметтагы билгенең гади дәрәҗәдәгедән кимрәк булуын белдерә. Сыйфатның кимлек дәрәҗәсе **-су, -ча, -сыл, -сел, -мса, -гылт, -гелт, -кылтым, -келтем, -елҗем** кебек кушымчалар ярдәмендә ясала: ал + су — алсу, җылым + са — җылымса, салкын + ча — салкынча, күк + елҗем — күгелҗем, яшел + келт — яшькелт.

**Бирем.Шундый предметны тап.**

Түгәрәк, баллы, сусыл, эче кызыл, тышы яшел, полосалы.

Карбыз.



Җиңел, түгәрәк, зәңгәр, оча торган.

OPEN.AZ



Шар


Йомшак, ак, мыеклы, сөт ярата.



# Песи



Яшел,чәнечкеле,бизәлгән,
яңа елда куела.





Чыршы



Сары, озынча, әче, файдалы, җиләк – җимеш.

# Лимон



Түгәрәк, кызыл, кечкенә, төшле, тәмле.

OPEN.AZ

# Чия



**Табышмак әйтү.**

1.Үзе кып – кызыл, күлмәге ямь – яшел .

2.Җәен – соры, кышын – ак, аңа шулай яхшырак.

3.Су түгел – сыек,
Кар түгел – ап – ак.

4.Тышы сары, эче ак, ерактан торып елата.

5.Көмеш тәнле,ите и тәмле.